**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советы**
**Карары**

**«19» сентябрь 2019 ел** **№ 112**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум**

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында”гы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы “Җирле референдум турында”гы Татарстан Республикасы Законының 18 маддәсе, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Уставының 15 маддәсе, 2019 елның 18 нче сентябрендәге “Җирле референдум үткәрү инициативасы турында” Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Башкарма комитетының 43 номерлы карары, 2019 елның 19 нчы сентябрендәге “Җирле референдум үткәрү инициативасы турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советының 111 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. 2019 елның 17 ноябренә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә

.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге территориясендә турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән, (кондезге бүлектә укучы студентлардан кала) җирлек территориясендә тавыш бирү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме:
- Олы Салтык авылында юлларны ремонтлау,
- Олы Мәрәтхуҗа авылында зират коймасын ремонтлау,
- Каты көнкүреш калдыклары полигоннарын норматив хәлгә китерү,

-  Олы Салтык авылында кое ремонтлау,
-  Даныш  авылында кулне чистарту.
3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов ур., 126 йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Мөрәтхуҗа авылы, Ленин урамы, 61йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71, шулай ук “Волжские зори” (“Идел таннары”) газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Олы Салтык авыл җирлеге башлыгы Х. Х. Ибәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авылы җирлеге
Башлыгы, Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль
районы Олы Салтык авыл
җирлеге Советы рәисе                                                  Х.Х. Ибәтов